**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
423100, Чирмешән авылы, Совет урамы, 32 йорт

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

18 июль 2019 ел **Чирмешән** **№ 312**

# КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының “2019 елда социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы пенсионерларның, ветераннарның, инвалидларның иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 2019 елның 8 апрелендәге 135 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында” (2018 елның 20 ноябрендәге үзшәрешләр белән) 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 8 апрелендәге 135 номерлы карары белән расланган “2019 елда социаль әһәмиятле эшчәнлекне гамәлгә ашыручы пенсионерлар, ветераннар, инвалидлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе” нә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында:

1.1. 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: “Субсидия алу өчен иҗтимагый оешма башкарма комитетка әлеге тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән документларны теркәп, субсидияләр бирү өчен гариза (финанс-бюджет палатасы тарафыннан расланган типик форма буенча) тапшыра.

Башкарма комитет гаризаны тәртипнең 6 пункты нигезендә, гаризалар теркәү журналына кергән көнне терки һәм әлеге тәртипнең 8 пункты нигезендә карар кабул итә.;

1.2. 7 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: “Субсидия бирүдән баш тарту турында Карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә, Башкарма комитет хәбәрнамә кушып, иҗтимагый оешма документларын кире кайтара, анда кабул ителгән карарның нигезләре күрсәтелә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

әлеге тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән субсидияләр бирү таләпләренә һәм шартларына иҗтимагый оешманың туры килмәве;

әлеге тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);

иҗтимагый оешма биргән мәгълүматның дөрес түгеллеге;

бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау”.

1.3. 8 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә “Өч эш көне эчендә Башкарма комитет һәм субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән типик форма буенча субсидия бирү турында Килешүгә кул куя.

1.4. 9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә “Субсидияләр Татарстан Республикасы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән типовой форма нигезендә төзелгән субсидия бирү турындагы килешү нигезендә бирелә.

Иҗтимагый оешма тарафыннан бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$V = S \times Z$,

где

V – субсидия күләме

S – җитештерү чыгымнары

Z – субсидия ставкасы

Субсидия бирү турында килешүдә карала:

- субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

- финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган субсидия чыгымнарның юнәлешләре;

- субсидия күчерү тәртибе;

- иҗтимагый оешма тарафыннан чыгымнарны бюджеттан тыш (шәхси) финанслау буенча субсидияләр булган чыгымнар турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формалары;

- финансны хисаплаганда, агымдагы финанс елында файдаланылмый калган субсидияләрнең калдыкларын кире кайтару тәртибе;

- иҗтимагый оешманың район Башкарма комитеты, Финанс-бюджет палатасы, Контроль-хисап палатасы тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалыгы».

1.5. 14 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: “Район Башкарма комитеты һәм финанс-бюджет Палатасы, районның Контроль - хисап палатасы субсидия алучыларга акча бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерә".

1.6. 1,2,3,4 кушымталарын үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны рәсми хокукый порталда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район башкарма комитеты
җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин